**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2021елның 06 сентябре 2518 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм махсус салым «Һөнәри керемгә салым» режимын кулланучы физик затларга ярдәм күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга 14.1 статьясын кертү өлешендә үзгәрешләр кертелүгә һәм махсус салым режимын кулланучы физик затлар тарафыннан ярдәм чаралары күрү мөмкинлеген билгеләүгә бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2007 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 24 сентябрендәге 3404 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм махсус салым «һөнәри керемгә салым» режимын кулланучы физик затларга ярдәм күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен расларга (алга таба - исемлек).
3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.
4 . Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лаеш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасына йөкләргә.

Җитәкче А.А.Новиков

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Башкарма комитетының 2021 елның 6 сентябрендәге
2518 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм махсус салым «Һөнәри керемгә салым» режимын кулланучы физик затларга ярдәм күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибе**

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы милкендә булган, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, шәхси эшмәкәрләр булмаган һәм махсус салым «Һөнәри керемгә салым» режимын кулланучы физик затларга ярдәм күрсәтү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару процедурасын, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында»2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында билгели.

2. Исемлеккә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы милкендә булган күчемле һәм күчемсез милек, өченче затларның хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш) буш булган күчемсез милек, шул исәптән җир кишәрлекләре, биналар, төзелешләр, корылмалар, торак булмаган биналар, җайланмалар, машиналар, механизмнар, урнаштыру, транспорт чаралары, инвентарь, инструментлар керә.

3. Исемлеккә кертелгән мөлкәт бары тик кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, шәхси эшкуарлар булмаган һәм «һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга,файдалану, биләү максатларында файдаланылырга мөмкин, шул исәптән арендага, һәм «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2.1 өлеше нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләүле нигездә читләштерелергә мөмкин.

4. Исемлек «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлешендә күрсәтелгән дәүләт мөлкәтенең һәм муниципаль мөлкәтнең расланган исемлекләре турында белешмәләр тапшыру тәртибен раслау хакында» Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2016 елның 20 апрелендәге 264 номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча кәгазь һәм электрон чыганакларда, шулай ук мондый исемлекләргә кертелгән үзгәрешләр турында «Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча федераль корпорация» акционер җәмгыятенә җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләре ел саен 1 октябрьгә кадәр Лаеш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының файдаланылмаган муниципаль мөлкәте турында, аларга хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мәгълүматны, мондый мөлкәтне исемлеккә кертү максатыннан, шулай ук мөлкәтне исемлектән төшереп калдыру турында тәкъдимнәр җибәрә.

6. Лаеш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы ел саен, 1 декабрьгә кадәр:

тәкъдим ителгән мәгълүматны һәм тәкъдимнәрне карый, исемлекне раслау өчен вәкаләтле органга төзи һәм җибәрә;

Исемлекне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыра, шулай ук «Кама ягы» («Камская Новь») газетасында бастыра.

7.Исемлекне раслау Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

Район эшләре идарәчесе В.Н.Воробьев